# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ
# КАРАР

21.11.2016 № 100

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 20 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдум да катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьялары нигезендә Арча районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беренче нөсхәсе мәгълүматлары нигезендә җирле референдум нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча беркетмә төзеде:

"2017 елда Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

-юлларга вак таш салу.:

Яңа Кырлай авылы Тукай урамы 70тән 95кә кадәр; Яшел урамы, Яшьләр урамы;

Яңа Иябаш авылы Татарстан ур., Яшьләр ур.;

Өчиле авылы Яңа ур., Җиңүнең 65 еллыгы ур.;

Чиканас авылы Совет ур., Октябрь ур. 27-51;

Иске Юрт авылы Аркылы ур., Клуб ур.;

Югары Бирәзә авылы Комсомол ур., Бахча-Сарай ур.;

Күкчә-Бирәзә авылы, Үзәк ур. 1-11, Починок ур.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга".

Референдум нәтиҗәләретурындаберкетмәнигезендә:

Референдумдакатнашучыларисемлегенәтавышбирүтәмамланугa 1412 референдумдакатнашучыкертелгән, тавышбирүдәреферендумдакатнашучылар саны-1242, бу 87,96% тәшкилитә.

Тавышбирүнәтиҗәләребуенчареферендумдакатнашучыларныңтавышлар ытүбәндәгечәбүленде:

«Әйе» позициясеөчен 1121 референдумдакатнашучытавышбирде, бу 90,26% тәшкилитә; «Юк» позициясеөченреферендумдакатнашкан 121 кешетавышбирде, бу 9,74% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган, референдум нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. "2017 елда Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

-юлларга вак таш салу.:

Яңа Кырлай авылы Тукай урамы, 70тән 95кә кадәр; Яшел урамы, Яшьләр урамы;

Яңа Иябаш авылы Татарстан ур., Яшьләр ур.;

Өчиле авылы Яңа ур., Җиңүнең 65 еллыгы ур.;

Чиканас авылы Совет ур., Октябрь ур. 27-51;

Иске Юрт авылы Аркылы ур., Клуб ур.;

Югары Бирәзә авылы Комсомол ур., Бахча-Сарай ур.;

Күкчә-Бирәзә авылы, Үзәк ур. 1-11, Починок ур.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга".

соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3.Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru. http:pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
Территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
Территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева